РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
АЛЬМЕТЬЕВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ӘЛМӘТ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«5» декабрь 2023 ел г. Альметьевск № 7578

Әлмәт муниципаль районы Башкарма комитетының «Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районының муниципаль норматив хокукый актлар проектларының җайга салу йогынтысын бәяләүне уздыру һәм муниципаль норматив хокукый актларына экспертиза ясау турындагы нигезләмәне раслау хакында» 2017 елның 01 августындагы 1226 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында

«Россия Федерациясендә дәүләт контроле (күзәтчелеге) һәм муниципаль контроль турында» Федераль закон кабул ителүгә бәйле рәвештә Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» 2021 елның 11 июнендәге 170-ФЗ номерлы Федераль закон, Татарстан Республикасы норматив хокукый актлары проектларының җайга салу йогынтысын бәяләүне уздыру һәм Татарстан Республикасы норматив хокукый актларына экспертиза ясау тәртибе турында» 2014 елның 07 мартындагы 14-ТРЗ номерлы закон нигезендә

БАШКАРМА КОМИТЕТ КАРАР БИРӘ:

1. Әлмәт муниципаль районы Башкарма комитетының «Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районының муниципаль норматив хокукый актлар проектларының җайга салу йогынтысын бәяләүне уздыру һәм муниципаль норматив хокукый актларына экспертиза ясау турындагы нигезләмәне раслау хакында» 2017 елның 01 августындагы 1226 номерлы карарына (Әлмәт муниципаль районы Башкарма комитетының 2021 елның 5 мартындагы 292 номерлы карары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

карарга 1 нче кушымтада:

1 бүлекнең 1.1 пунктының икенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Актлар проектларының җайга салу йогынтысын бәяләү, гамәлдәге

норматив актларга экспертиза эшкуарлык һәм башка икътисадый эшчәнлек субъектлары өчен артык бурычлар, тыюлар һәм чикләүләр кертә торган яисә аларны кертүгә этәрә торган нигезләмәләрне, шулай ук эшкуарлык һәм башка икътисадый эшчәнлек субъектларының, муниципаль берәмлек бюджетының нигезләнмәгән чыгымнарын барлыкка китерүче нигезләмәләрне ачыклау максатларында уздырыла.»;

1 бүлекнең 1.2 пунктындагы 1.2.6 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1.2.6. эшкуарлык һәм башка икътисадый эшчәнлек субъектлары өчен, инвестиция эшчәнлеге субъектлары өчен яңа яисә муниципаль норматив хокукый актларда каралган мәҗбүри таләпләрне, бурычларны билгеләү»;

2 бүлекнең 2.3 пунктындагы 6 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«6) муниципаль җайга салу җибәрелгән эшкуарлык эшчәнлеге субъектлары төркеменә һәм башка икътисадый эшчәнлеккә, инвестиция эшчәнлеге субъектларына характеристика»;

2 бүлекнең 2.3 пунктындагы 8 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«8) билгеләнгән вазыйфаларны үтәү яисә чикләүләрне үтәү зарурлыгына яисә мондый вазыйфаларның эчтәлеген яисә чикләүләрне үзгәртүгә бәйле муниципаль бюджет, эшкуарлык эшчәнлеге субъектларының һәм башка икътисадый эшчәнлек субъектларының, инвестиция эшчәнлеге субъектларының чыгымнарын (кертемнәрен) бәяләү»;

3 бүлекнең 3.5 пунктындагы 2 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2) акт проектында эшкуарлык һәм башка икътисадый эшчәнлек субъектлары өчен мәҗбүри таләпләрне һәм бурычларны, инвестиция эшчәнлеге субъектлары өчен бурычларны яисә аларны алып баруга ярдәм итә торган нигезләмәләрне ачыклау»;

3 бүлекнең 3.5 пунктындагы 4 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4) акт проектының эшкуарлык һәм башка икътисадый эшчәнлек субъектлары өчен дә, инвестиция эшчәнлеге субъектлары өчен дә, тулаем җәмгыять өчен дә файдасын һәм чыгымнарын бәяләүне, шулай ук акт проекты максатларына ирешү куркынычын төгәлләштерү»;

Карар Нигезләмәсенә 1 нче кушымтада:

1 нче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы башкарма комитетының сәүдә, кулланучылар хезмәтләре күрсәтү һәм эшкуарлык үсеше бүлеге муниципаль норматив хокукый актлар проектларының җайга салу йогынтысын бәяләүне уздыру нигезләмәсенең 3 пункты нигезендә (алга таба Нигезләмә) әлеге ____________________________________________

(Әлмәт муниципаль районының җирле үзидарә органы исеме)

бәяләмәсен әзерләү өчен әзерләнгән һәм җибәрелгән проектны____________________________________________

(муниципаль хокукый акт исеме)

(алга таба - акт проекты) карады, түбәндәгеләр хәбәр итә».

1.5 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1.5. Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Башкарма комитетының сәүдә, кулланучылар хезмәтләре күрсәтү һәм эшкуарлыкны үстерү бүлеге яисә ачык консультацияләр әзерләүче турында мәгълүмат:

____________________________________________

(вакыты, катнашучылар һәм тәкъдимнәр саны)

2 бүлекнең 2.2.1 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2.2.1 эшкуарлык һәм башка икътисадый эшчәнлек субъектлары өчен административ һәм башка чикләүләр һәм мәҗбүри таләпләр һәм бурычлар, инвестиция эшчәнлеге һәм башка эшчәнлек субъектлары өчен бурычлар кертәләр яисә аларны кертүгә ярдәм итәләр:

______________________________________________________________».

(текстлы тасвирлау өчен урын)

2. Әлеге карарны «Альметьевский вестник» газетасында бастырып чыгарырга, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (PRAVO.TATARSTAN.RU) урнаштырырга.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыкканнан соң үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны район Башкарма комитеты җитәкчесенең икътисад буенча урынбасары вазыйфаларын башкаручы А.Ә. Ямалетдиновка йөкләргә.

Район
Башкарма комитеты җитәкчесе
вазыйфаларын башкаручы — А.Р. Исхаков